**Республика Татарстан**
**Руководитель Исполнительного комитета Бухарайского сельского поселения Заинского муниципального района**
Ул. Новая, д. 4, с. Бухарай,
Заинский район, 423536

**Татарстан Республикасы Зәймуниципаль районы Бохарайавылҗирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе**
Яна урамы, 4нчейорт,
Бохарайавылы, Зәй районы,
423536

Телефон, факс 6-77-34. Электронный адрес: Buhar.zai@tatar.ru, сайт: www.Buhar.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№15** **21 декабря 2023 год**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы, "Бохарай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Бохарайавылҗирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Е.В. Груздева

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы Бохарай
авыл җирлеге башкарма
комитетының 21.12.2023 ел,
№15 карарына 1 нче
кушымта.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенә гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе

1. 1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенә (алга таба - авыл җирлеге) кергән коррупция һәм янау фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урынынан явызларча файдалану билгеләре булган авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре кылган башка гамәлләр, шулай ук муниципаль хезмәт Вазыйфалары булып тормаган һәм авыл җирлеге эшчәнлегенә техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган коррупциячел юнәлеше фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен(алга таба - мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели.

Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә керә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать " Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында "2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

3. Коррупция юнәлеше фактлары буенча мөрәҗәгатьләрне карау өчен җаваплы зат Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге башкарма комитет җитәкчесе булып тора.

4. Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яки кылынган законсыз гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки кылган кеше турында мәгълүматлар булганда, мөрәҗәгатьне аларның компетенциясенә ярашлы рәвештә хокук саклау органнарына җибәрергә кирәк.

5. Мөрәҗәгатьне караганда, андагы белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Карала торган мәсьәләнең барлык шартларын ачыклаганчы мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне җибәрү гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне таратуга керми.

6. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең саклнышы өчен җаваплы.

7.Карары яки гамәл кылуы (кылмавы) мөрәҗәгать итү предметы булып тор ган органга яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать җибәрелми.

8. Мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча бирелгән җавапта, үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре һәм тикшерүләр турында мәгълүмат, шулай ук кабул ителгән чаралар, шул исәптән вазыйфаи затка карата җаваплылык чараларын куллану яки тикшерү үткәрү өчен нигезләр булмау һәм коррупция фактлары расланмавы турында мәгълүмат булырга тиеш.